Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданка Р.Н. Садыйкова шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 5.4.2 пунктындагы дүртенче абзацының, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында” 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 сентябрендәге 774 номерлы карарының 1 пунктындагы өченче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре — 2020 елның 17 ноябре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 5.4.2 пунктындагы дүртенче абзацының, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында” 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 сентябрендәге 774 номерлы карарының 1 пунктындагы өченче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка Р.Н. Садыйкова шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Ф.Р. Волкова мәгълүматын, яклар — гражданка Р.Н. Садыйкова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының юридик бүлеге әйдәүче консультанты Р.Җ. Асьмаева, суд утырышына чакырылган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы вәкиле — Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының инвалидлар белән эшләү бүлеге башлыгы З.В. Мусабирова аңлатмаларын тыңлаганнан соң, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Р.Н. Садыйкова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 5.3.1 пунктындагы өченче абзацы белән һәм 5.4.2 пунктындагы дүртенче абзацы белән, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында” 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 сентябрендәге 774 номерлы карарының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 774 номерлы карары) 1 пунктындагы өченче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Тәртипнең Р.Н. Садыйкова мөрәҗәгать иткән вакытка гамәлдә булган редакциясендә 5.3.1 пунктындагы өченче абзацы нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдалануга сорау аларны күрсәтү мөмкинлегеннән артып киткән очракта, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларны социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче исәпкә ала торган чират нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тәртипнең 5.4.2 пунктындагы дүртенче абзацында каралганча, социаль хезмәт күрсәтү вакытын озайту турында карар социаль хезмәтләр күрсәтүнең соңгы көнендә инвалид (инвалид бала) мотивацион яктан әзер булганда

(тернәкләндерү чараларына регуляр йөргәндә, тернәкләндерү дәресләренә йөргәндә, тәкъдимнамәләрне үтәгәндә), тернәкләндерү чараларын үткәрү нәтиҗәсендә уңай динамика күзәтелгәндә кабул ителә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 774 номерлы карарының 1 пунктындагы өченче абзацы белән Тәртипнең 5.4.2 пунктындагы беренче абзацында «21 эш көне» сүзләре «15 эш көне» сүзләренә алыштырылган.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Р.Н. Садыйкова үзенең балачактан I төркем инвалид булган 1997 елда туган кызының законлы вәкиле булып тора. 2016 елның июнендә, аның Казан шәһәре Идел буе районы социаль яклау бүлегенә мөрәҗәгатеннән соң, кызы өчен, инвалидларны тернәкләндерү үзәгенә озатып йөрүче зат белән бергә чиратка куеп, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы эшләнгән. Әмма, мөрәҗәгать итүче билгеләп үткәнчә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм аның территориаль органына берничә тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң гына бары тик 2018 елда гына тернәкләндерү тәкъдим ителгән.

Гражданка Р.Н. Садыйкова үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуын Тәртипнең 5.3.1 пунктындагы өченче абзацының, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучыларны кабул итү өчен чиратлылык принцибын билгеләп, аны формалаштыру критерийларын (инвалидлык дәрәҗәсен, гариза бирү датасын һ.б.) күздә тотмауда, шуның белән социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчегә аны ирекле рәвештә формалаштырырга мөмкинлек биреп, моның тернәкләндерүгә җибәрү срокларын сузуга китерүендә күрә.

Тәртипнең 5.4.2 пунктының дүртенче абзацындагы нигезләмә, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, шулай ук социаль хезмәт күрсәтү вакытын озайту турында карар кабул итүне социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең ирекле каравына калдыра, чөнки шикаять белдерелә торган нормада санап үтелгән шартлар —

инвалид (инвалид бала) мотивацион яктан әзер булу (тернәкләндерү чараларына регуляр йөрү, тернәкләндерү дәресләренә йөрү, тәкъдимнамәләрне үтәү) һәм тернәкләндерү чараларын үткәрү нәтиҗәсендә уңай динамика күзәтелү — төгәл түгел һәм аларны бәяләгәндә субъектив якын килү мөмкинлегенә юл куя.

Гражданка Р.Н. Садыйкова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 774 номерлы карарының 1 пунктындагы өченче абзацында каралган тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидлар өчен социаль хезмәтләр күрсәтү вакытын берни белән дә нигезләнмәгән 21 эш көненнән 15 көнгә кадәр киметүне социаль тәэминатка конституциячел хокукларны чикләү дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 5.3.1 пунктындагы өченче абзацының һәм 5.4.2 пунктындагы дүртенче абзацының, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында" 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 сентябрендәге 774 номерлы карарының 1 пунктындагы өченче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 31 (икенче өлеш), 38 (беренче өлеш), 52 (беренче өлеш) һәм 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм иркле үсеш

тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең яки аларга өстенлекләр билгеләүнең теләсә кайсы рәвеше тыела; кеше гомере, аның сәламәтлеге, шәхси ирекге һәм иминлеге дәүләт яклавында; гаилә, ана булу, ата булу, балачак һәм картлык дәүләт яклавында; Татарстан Республикасында һәркем, сәламәтлек саклауның дәүләт һәм бүтән учреждениеләре законда билгеләнгән тәртиптә күрсәтә торган медицина ярдәмен дә кертеп, сәламәтлеген саклауга хокуклы; һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән очракта һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә.

1.1. Татарстан Республикасы Конституция судының 2020 елның 26 мартындагы 8-О номерлы билгеләмәсе белән гражданка Р.Н. Садыйкова шикаяте карауга алынган иде.

Суд утырышында эшне карый башлаганчы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 апрелендәге 285 номерлы карары белән мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган Тәртипнең 5.3.1 пунктындагы өченче абзацына үзгәрешләр кертелде. 5.3.1 пунктындагы дәгъва белдерелә торган нигезләмәнең гамәлдәге редакциясе социаль хезмәт күрсәтүләрне тиешле социаль хезмәт күрсәтү белән тәэмин итүчедән алуга ихтыяҗ аларны күрсәтү мөмкинлегеннән арткан очракта социаль хезмәтләрне алучыларны социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче формалаштыра торган чират нигезендә гамәлгә ашырылуын күздә тота. Тиешле тәртип Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан 2020 елның 3 июлендәге 484 номерлы боерыгы белән расланган.

Эшне тыңлауга билгеләгәннән соң кертелгән үзгәрешләр белән бәйле

рәвештә гражданка Р.Н. Садыйкова шикаятькә төгәлләштерү җибәрде, аның нигезендә ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 5.3.1 пунктындагы өченче абзацының конституциячеллеген тикшерү өлешендә таләптән баш тарта һәм күрсәтелгән Тәртипнең 5.4.2 пунктындагы дүртенче абзацын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 774 номерлы карарының 1 пунктындагы өченче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тануны сорый.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы икенче өлеше белән билгеләнгәнчә, конституциячеллеге дәгъвалана торган акт эшне карый башлаганда яисә карау чорында юкка чыгарылган булса яисә үз көчен югалтса, Татарстан Республикасы Конституция судының башланган эше туктатылырга мөмкин, моңа акт белән гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылган очраклар керми. Югарыда аталган Законның 47 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына бирелгән мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында эшне карый башлаганчы ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан кире алынырга мөмкин. Мөрәҗәгать кире алынган очракта эшне карау туктатыла. Мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган хокукый нигезләмәгә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, шулай ук шикаятькә ачыклык керткәндә аның үз таләпләренең бер өлешеннән баш тартуын игътибарга алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 5.3.1 пунктындагы өченче

абзацының конституциячеллеген тикшерүгә кагылышлы өлешендә эш башкару туктатылырга тиеш.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора:

— Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 5.4.2 пунктындагы дүртенче абзацы, социаль хезмәт күрсәтү вакытын озайту турында карар социаль хезмәтләр күрсәтүнең соңгы көнендә инвалид (инвалид бала) мотивацион яктан әзер булганда (тернәкләндерү чараларына регуляр йөргәндә, тернәкләндерү дәресләренә йөргәндә, тәкъдимнамәләрне үтәгәндә) һәм тернәкләндерү чараларын үткәрү нәтиҗәсендә уңай динамика күзәтелгәндә кабул ителүен күздә тотып, билгеләнгән шартларны бәяләүнең төгәл критерийларын беркетмәгән дәрәҗәдә;

— «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында” 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче

карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 сентябрендәге 774 номерлы карарының 1 пунктындагы өченче абзацы, анда инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидлар өчен социаль хезмәтләр күрсәтү дәвамлылыгы 21 эш көненнән 15 көнгә кадәр киметелгән дәрәҗәдә.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау өлкәсенә карый, ул Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» пункты) нигезендә Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында, шуңа күрә Татарстан Республикасы әлеге өлкәдә хокукый җайга салуны федераль законнар нигезендә һәм аның законнары, башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килмәсә генә, гамәлгә ашырырга хокуклы (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясындагы 2 һәм 5 өлешләр).

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба шулай ук — «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» Федераль закон) Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтүнең хокукый, оештыру һәм экономик нигезләрен, федераль дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарының гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтләрен, социаль хезмәтләр алучыларның һәм социаль хезмәтләр күрсәтүчеләрнең хокук һәм бурычларын билгеләүче махсус закон булып тора. Күрсәтелгән Федераль законның 8 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарының социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтләренә шул исәптән социаль хезмәтләр күрсәтүчеләрнең социаль хезмәт күрсәтүләре тәртибен раслау керә (10 пункт).

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» Федераль законның күрсәтелгән норматив нигезләмәләрен үстерү йөзеннән «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән, аның нигезендә социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә керә (4 статьяның 8 пункты).

Шулай итеп, аерым нигезләмәләренә карата гражданка Р.Н. Садыйкова тарафыннан шикаять белдерелә торган «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карарын, шулай ук югарыда күрсәтелгән Тәртипкә үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 774 номерлы карарын кабул итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль һәм республика законнары нигезендә карый торган һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, алар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты социаль тәэминат өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара, аларның үтәлешен тикшерә.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар

булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт булуын танып, һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән, туендыручысын югалткан очракта һәм законда билгеләнгән башка очракларда балаларны тәрбияләү өчен социаль тәэминат гарантияләнү (13 статья һәм 54 статьяның беренче өлеше) хокукын кеше һәм гражданның төп хокуклары һәм ирекләре итеп беркетә. Мәгънәсе буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясе белән билгеләнгән (7 статья һәм 39 статьяның 1 өлеше).

Әлеге конституциячел нормалар 1996 елның 3 маендагы Европа социаль хартиясенең (яңадан каралган) 15 статьясындагы якларның, аерым алганда, инвалидларга тулы социаль интеграциягә һәм җәмгыять тормышында катнашуга хокукны нәтиҗәле гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итү бурычын күздә тота торган нигезләмәләренә, шулай ук Инвалидлар хокуклары турындагы конвенциянең (БМО Генераль Ассамблеясы тарафыннан 2006 елның 13 декабрендә кабул ителгән, 2012 елның 3 маендагы 46-ФЗ номерлы Федераль закон белән ратификацияләнгән) инвалидларның лаеклы тормыш дәрәҗәсенә һәм социаль яклауга хокукын шулай ук таный торган 28 статьясына туры килеп торалар.

Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр күрсәткәнчә, гражданнарның теге яисә бу категорияләренә күрсәтелә торган социаль яклауның конкрет алымнарын һәм күләмнәрен билгеләү закон чыгаручының өстенлекле хокукы булып тора, ул социаль яклау чараларын билгеләгәндә, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлап алуда, күрсәтелү шартларын регламентлаштыруда шактый ирекле карау мөмкинлегенә ия; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) — акчалата яисә натураль, сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы, 2016 елның 13 апрелендәге 11-П номерлы карарлар; 2014 елның 4 февралендәге 236-О номерлы, 2014 елның 18 сентябрендәге 1821-О номерлы, 2015 елның 9 июнендәге 1230-О номерлы билгеләмәләр).

3.1. Гражданка Р.Н. Садыйкова шикаять белдерә торган Тәртипнең 5.4.2 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә социаль хезмәт күрсәтү

вакытын озайту турында карар социаль хезмәтләр күрсәтүнең соңгы көнендә инвалид (инвалид бала) мотивацион яктан әзер булганда (тернәкләндерү чараларына регуляр йөргәндә, тернәкләндерү дәресләренә йөргәндә, тәкъдимнамәләрне үтәгәндә) һәм тернәкләндерү чараларын үткәрү нәтиҗәсендә уңай динамика күзәтелгәндә кабул ителә. Әлеге нигезләмә гамәлдәге хокукый җайга салу системасында үзенең эчтәлеге һәм максатчан билгеләнеше буенча инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү механизмы элементы булып тора, ул дәгъва белдерелә торган Тәртипнең V бүлегендә җентекләп көйләнгән.

Шулай, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр эшчәнлегенә карата таләпләр Тәртипнең 5.3 бүлекчәсендә регламентлаштырылган, аның белән, аерым алганда, социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү һәм хезмәт күрсәтүдән чыгару социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче приказы белән рәсмиләштерелә, социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының һәркайсына аңа социаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның күчермәләре, социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамә кертелә торган шәхси эш формалаштырыла; социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы һәр кешегә социаль хезмәт күрсәтүгә кабул иткәндә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча тернәкләндерү картасы төзелә дип билгеләнә (Тәртипнең 5.3.2 пункты).

Әлеге норманы гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан 2020 елның 30 маендагы 303 номерлы боерык белән инвалидны тернәкләндерү һәм абилитацияләү карталарының бер типтагы формалары расланган, алар шул исәптән түбәндәгеләрне күрсәтүне (чагылдыруны (билгеләп баруны), тутыруны) күздә тота: тернәкләндерү чараларының максатлары, социаль хезмәт күрсәтү оешмасына кергәндә социаль хезмәт күрсәтүдән файдаланучыга беренчел белешмәләр; медицина-социаль экспертиза учреждениесе тарафыннан билгеләнгән социаль хезмәт күрсәтүдән

файдаланучының тернәкләндерү потенциалы; планлаштырылган чаралар исемлеге; фаразлана торган нәтиҗәләр; агымдагы тернәкләндерү курсына тернәкләндерү һәм абилитация программалары; социаль тернәкләндерү һәм абилитация программасын үтәү; учреждениенең Эксперт советы тарафыннан тернәкләндерү чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләре; тернәкләндерү чараларын үтәү нәтиҗәләре турында бәяләмә.

Тәртиптә каралганча, социаль хезмәтләр күрсәтүне планлаштыру һәм күрсәтү этаплар буенча гамәлгә ашырыла, аерым алганда: диагностикалаудан, тернәкләндерү гамәлләрен тормышка ашыруның индивидуаль планын эшләүдән башлана, аннан соң тернәкләндерү гамәлләрен тормышка ашыру этабы бара, аннары — тернәкләндерү гамәлләрен үткәрү барышын мониторинглау (күзәтү) һәм ахырда тернәкләндерү гамәлләренең нәтиҗәлелеген бәяләү башкарыла (Тәртипнең 5.3.3 пункты).

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» Федераль законның 27 статьясы таләпләре нигезендә Тәртипнең 5.4 бүлекчәсендә, аңа 4 нче кушымта белән үзара бәйләнештә, Социаль хезмәтләр күрсәтү стандарты каралган, ул шул исәптән инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү исемнәрен, тасвирламасын һәм аларны күрсәтү күләмнәрен, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен бәяләүне һәм аларның сыйфаты күрсәткечләрен, социаль хезмәтләр күрсәтү вакытын үз эченә ала.

Тәртипнең 5.4.2 пунктының беренче абзацында социаль хезмәтләр күрсәтү социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә һәм, аерым алганда, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидлар өчен 15 эш көне тәшкил итәргә тиеш дип билгеләнгән. Шуның белән бергә, әлеге пунктның 3 абзацы нигезләмәләреннән күренгәнчә, бу чор инвалидның (аның законлы вәкиленең) социаль хезмәт күрсәтү вакыты чыкканга кадәр социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең эш

көннәрендә исәпләнә торган 5 көннән дә соңга калмыйча тапшырылган тиешле гаризасы нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көнгә кадәр озайтылырга мөмкин.

Тәртипнең 5.3.3 пункты нигезендә социаль хезмәт күрсәтү вакытын озайту зарурлыгы составы һәм аның эш регламенты социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче приказы белән раслана торган Эксперт советы тарафыннан билгеләнә. Шулай ук ул анда социаль хезмәт күрсәтү кысаларында тернәкләндерү чараларының инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитациясе индивидуаль программасында күрсәтелгән федераль медицина-социаль экспертиза учреждениесе тәкъдимнамәләре исәпкә алынган индивидуаль планын эшли һәм аларны үткәрүнең нәтиҗәлелеген анализлый.

Югарыда бәян ителгәннәрдән аңлашылганча, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәткәндә тернәкләндерү гамәлләрен үткәрү барышы мониторинглана (күзәтелә), тернәкләндерү гамәлләренең нәтиҗәлелеге бәяләнә һәм алар тернәкләндерү һәм абилитация карталарында чагылдырыла (билгеләп барыла), бу Эксперт советы тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү вакытын озайту зарурлыгын билгеләгәндә Тәртипнең 5.4.2 пунктындагы шикаять белдерелә торган дүртенче абзацында каралган мотивацион яктан әзер булу һәм тернәкләндерү чараларын үткәрү нәтиҗәсендә уңай динамика турындагы шартлар белән беррәттән нигез итеп алына. Моннан социаль хезмәт күрсәтү вакытын озайту зарурлыгы, мөрәҗәгать итүче дәлилләренә карамастан, ирекле билгеләнми, ә инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләр алуның объектив күрсәткечләре нигезендә билгеләнә дигән нәтиҗә ясарга була.

Тәртипнең югарыда аталган норматив хокукый нигезләмәләрен анализлаудан һәм системалы аңлатудан чыгып, Татарстан Республикасы Конституция суды социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү вакытын арттыру зарурлыгы билгеләнә торган шартлар Тәртиптә җитәрлек дәрәҗәдә ачык билгеләнгән дигән нәтиҗәгә килә,

моннан мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Тәртипнең 5.4.2 пунктындагы дүртенче абзацы нигезләмәсе үзенең эчтәлеге һәм конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча гражданнарның, шул исәптән гражданка Р.Н. Садыйкованың конституциячел хокукларын юкка чыгармый, киметми һәм башкача бозмый һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28, 52 һәм 54 статьяларына каршы килмәгәнлеге килеп чыга. Шуның белән бергә бәян ителгәннәр, мәсәлән, үзенең алдагы гамәлләрен үз вакытында планлаштырырга, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү оешмасыннан чыгуны оештырырга мөмкинлеге булсын өчен карар кабул итү турында гражданга алдан хәбәр итү өлешендә социаль хезмәт күрсәтүне озайту турында карар кабул итү тәртибен хокукый җайга салуны камилләштерү мөмкинлеген юкка чыгармый.

3.2. Россия Федерациясе Конституция Суды гражданнарның хокукый хәленә тискәре йогынты ясый торган гамәлдәге хокукый җайга салуга үзгәрешләр кертү гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын хуплау принцибы саклану белән бергә алып барылырга тиеш, ул хокукый җайга салуның нигезле тотрыклылыгын саклап калуны һәм гамәлдәге нормалар системасына законсыз үзгәрешләр кертүгә юл куелмауны күз алдында тота; тиешле хокукый мөнәсәбәтләрдә катнашучылар нигезле чикләрдә үз халәтенең нәтиҗәләрен алдан күрү мөмкинлегенә ия булырга һәм үзенең рәсми танылган статусының, алган хокукларының үзгәрешсез калуына, аларның дәүләт тарафыннан яклануының тәэсирлелегенә ышанычы булырга тиеш дип берничә тапкыр ассызыклады (2001 елның 24 маендагы 8-П номерлы, 2011 елның 20 июлендәге 20-П номерлы, 2016 елның 15 февралендәге 3-П номерлы карарлар; 2013 елның 16 июлендәге 1071-О номерлы, 2015 елның 22 декабрендәге 2991-О номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Шулай итеп, хокукый җайга салуны гамәлгә ашырганда, үзенә бирелгән дискрецион вәкаләтләр кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты җитәрлек дәрәҗәдә ирекле карау мөмкинлегенә ия, шул ук вакытта

ул чикләнмәгән түгел, ә конституциячел әһәмияттәге кыйммәтләр, гавами һәм шәхси мәнфәгатьләр балансын үтәү зарурлыгына нигезләнергә тиеш.

Тәртипнең 5.4.2 пунктындагы беренче абзацы нигезендә, 2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган редакциясендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү вакыты 21 эш көне тәшкил иткән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 774 номерлы карарының 1 пунктындагы өченче абзацы белән югарыда күрсәтелгән нигезләмәгә үзгәреш кертелгән, аның нигезендә инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтү вакыты 21 эш көненнән 15кә кадәр кыскартылган. Шул ук вакытта социаль хезмәтләр исемлеге үзгәрмәгән.

Әлеге Карар «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) 2019 елның 6 сентябрендә рәсми рәвештә басылып чыккан һәм, 2 пунктта күрсәтелгәнчә, 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә кергән.

Моннан күренгәнчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 774 номерлы карары белән кертелгән үзгәреш, закон кире көчкә ия булмый дигән гомумхокукый принцип нигезендә, социаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән һәм үз көченә кергәнче, ягъни 2020 елның 1 гыйнварына кадәр тиешле исәпкә куелган гражданнарга карата аны куллану мөмкинлеген күздә тотмаганлыгы килеп чыга. Димәк, социаль хезмәт күрсәтүдән файдалану хокукы 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән һәм гамәлгә ашырылмаган гражданнарга карата инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү вакыты, Тәртипнең 2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган 5.4.2 пунктындагы беренче абзацы редакциясендә каралганча, 21 эш көне тәшкил итәргә тиеш.

Дәгъва белдерелә торган норманы башкача аңлау һәм куллану инвалидлык очрагында гражданнарның социаль тәэминатка хокукларын яклау өлкәсендә норматив җайга салуның конституциячел әһәмиятле максатлары белән туры килмәслек һәм нигезсез булыр иде һәм котылгысыз рәвештә

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган хокукый җайга салуның нәтиҗәлелеген аның чын ихтыярына каршы сизелерлек киметүгә китерер иде.

Россия Федерациясе Конституция Судының кайбер карарларында чагылдырылган хокукый позициясе нигезендә, тиешле хокукый җайга салуны билгеләгәндә һәм аңа үзгәрешләр керткәндә закон чыгаручы тигезлекнең һәм гаделлекнең, гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын саклауның конституциячел принципларын үтәргә һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 55 статьясы (3 өлеш) нигезендә гражданнарның аерым категорияләре тарафыннан теге яисә бу хокукын гамәлгә ашыру шартларында, әгәр алар объектив акланган, нигезле булса һәм конституциячел әһәмиятле максатларны күздә тотса, ә бу максатларга ирешү өчен кулланыла торган хокукый чаралар аларга туры килә, аерымлыклар булырга мөмкин дигәннән чыгып эш итәргә тиеш (2001 елның 24 маендагы 8-П номерлы, 2007 елның 5 апрелендәге 5-П номерлы һәм 2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы карарлар, Россия Федерациясе Конституция Судының 2005 елның 27 декабрендәге 502-О номерлы билгеләмәсе).

Закон дәрәҗәсендә инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең нинди дә булса билгеле бер вакыты ачыкланмаган. Шуның белән бергә Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 30 июлендәге 500н номерлы боерыгы белән расланган Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның социаль хезмәт күрсәтүләргә индивидуаль ихтыяҗларын билгеләү буенча рекомендацияләрнең 4.5 пункты белән социаль хезмәт күрсәтү оешмасында социаль хезмәт күрсәтүдән файдаланучы вакытлыча (индивидуаль программа белән билгеләнгән вакытка) тәүлек буе яшәгәндә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү вакытын социаль хезмәт күрсәтүнең конкрет максатларына ирешү (мәсәлән, социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучының социаль тернәкләндерү яисә абилитацияләү курсын үтүе; даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ булган социаль

хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучының яшәвен тәэмин итү һәм аны даими караудан кыска вакытка гаиләне азат итү максатларында аны карау) белән чикләргә киңәш ителүен күз алдында тоту мөһим.

Гражданка Р.Н. Садыйкова дәгъва белдерә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 774 номерлы карары белән бер үк вакытта Тәртипнең 5.4.2 пунктындагы өченче абзацына үзгәреш кертелгән, анда инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтү вакыты 21 эш көненнән 30 көнгә кадәр арттырылуы күз алдында тотылган. Димәк, кертелгән үзгәрешләр нәтиҗәсендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең максималь вакыты, аны озайту мөмкинлеген исәпкә алып, 45 эш көне тәшкил итә, элек гамәлдә булган редакциясендә ул 42 эш көне тәшкил иткән.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 774 номерлы карары белән инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү вакытын 21 эш көненнән 15 көнгә кадәр үзгәртеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ гражданнарның күбрәк өлешен биләү максатларында, мәнфәгатьләр балансы принцибын үтәп һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең күләмен саклап калып, аларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларны нәтиҗәле файдалану зарурлыгыннан чыгып эш иткән.

Мондый хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Конституциясенең 13 статьясы нигезендә халыкны социаль яклау гарантияләрен тәэмин итәргә бурычлы социаль дәүләт максатлары белән яраша.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 774 номерлы карарының 1 пунктындагы өченче абзацы нигезләмәсе, аның дәлилләренә карамастан, тернәкләндерүнең индивидуаль программасында каралган күләмнәрдә

социаль хезмәтләр алуга гражданнарның хокукларын чикләми һәм әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дигән нәтиҗә ясый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 46 статьясындагы 2 өлешенә, 47 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 һәм 84 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 5.4.2 пунктындагы дүртенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында” 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 сентябрендәге 774 номерлы карарының 1 пунктындагы өченче абзацын, гамәлдәге хокукый җайга салу системасында үзенең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча, социаль хезмәт алу хокукына ия булган һәм үз көченә кергәнче, ягъни 2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлгә ашырылмаган гражданнарга карата аны куллану мөмкинлеген күздә тотмаган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы

Конституциясенә туры килә дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 5.3.1 пунктындагы өченче абзацының конституциячеллеген тикшерүгә кагылышлы өлешендә эш башкаруны туктатырга.

4. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

5. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 94-П**

**Конституционный суд**
**Республики Татарстан**